# СИБГАТ ХӘКИМ

*Поэмалар*

**Сибгат ХӘКИМ**

## ДӘВЕРЛӘР КАПКАСЫ
**(поэма)**

Бар шагыйрьләр җирдә купкан чакта,
Юл биргәндә бар да туктап чатта.
Бик аз гына шунда, бик аз гына,
КамАЗ белән бары намаз гына
Рифмалашмый калган заманда.
Мин дә йөрдем, йөрдем КамАЗда,
Июнь ае, июнь ахырлары,
Һич колачлый алмый акыл әле,
Хисләремнең ашыкканын беләм,
КамАЗ үзенең масштабы белән
Басты уйны, ник дим бөек КамАЗ?
Килә җавап уйны җыеп алгач:
«Кама монда, тарих үзе монда,
Утырды ул кереп шушы фонга»...
Сәлам биреп горур ил картына,
Кереп иске Чаллы зиратына,
Кереп рәттән шунда ЗАГСка,
Кереп рәттән яшьлек-сагышка,
Теләп бәхет шунда Чулпаннарга,
Гашыйк булып Чулпан – чор-таңнарга,
Туктап, карап мин һәм ун адымда,
Йөрдем иркен Җәлил урамында.
Йортлар, йортлар, бардыр канатлары,
Мин канатлы йортлар тарафдары.
Бер уйласаң, хәтта җәлләрлек тә,
Китәрләр күк очып зәңгәрлеккә.
Кранлаша заман, кранлаша,
Урал аша түгел, урам аша
Сөйләшкәндә Казан белән Уфа,
Сүзләренә илһам куша-куша,
Һәм рәхмәтләр әйтеп Ереванга
Яңа йортлар буйлап йөрдем анда.
Һәр халык үз төсен, хисен салып,
Йортларыңны синең китсен салып.
Ут йортларда кичеп ут алынса,
Калка Мәскәү, калка ерак Уфа.
Егетләре Вазыйх Мәүлековның
Гөмбәзенә үрләгәндә күкнең,
Йөрдем июнь эссесендә шул чак
Заманга тиң сүзгә-җырга сусап.
Чаллы кызы, яшь кенә бер кыздан:

– Сеңлем, дидем, каян мондый тузан?
– Тузаннан мин үзем җик күрәм.
Йөрәгенә җирнең җиттеләр...
Атып читкә бөтен чүп-чарын,
Аерып КамАЗ Болгар туфрагын,
Бодай үскән кара туфрагын,
Кара туфрак – дала туфрагын
Өйде бергә... Чаллы чал булды,
Тарихының өстен салдырды.
Алмыйм дигән кебек артыгын,
Шушы дигән кебек алтының,
Тау ясады... Басты алыплар...
Җырым, мине шунда алып бар.
Терелде күк Чаллы туфрагы,
Гасырларның данлы туфрагы:
Чаллы, чалгы, печән өсте чагы,
Арышларның, камышларның шавы,
Керәшен моңы анда Гәрдәленең,
Эзе-юлы анда һәр дәвернең,
Шаулады күк Болгар базарлары,
Кайнады күк корыч казаннары,
Дулкыннарын ярга какты сулар,
Тимерчеләр, оста бакырчылар
Туганнарча якын караш белән
Сөйләштеләр гүя КамАЗ белән.

Анда кинәт пәйда булды бары,
Пугачевның ярда быргылары
Уйнады күк, яши ул чак даны,
Гражданнар сугышы учаклары
Янды ярда, җирнең күп зары,
Күп болганган Болгар туфрагы.
Кара туфрак коры дары күк,
Миллион күзләр миңа карый күк,
Күпме сугыш, күпме дау булган,
Ята сулап шул җир... Тукланырга
Икмәк биргән. Халкы, туфрагына
Һәйкәл кебек тора элеватор:
Синме «Батыр» монда, минме батыр?
Югалды дип юкка уынма,
Ул туфракны шул ук урынга
Сипте КамАЗ, шул ук урынга –
Киләчәккә, яңа буынга.
Бу җирләрнең төтен, тузаны
Хәтерләтте миңа Дуганы...

Бар нигезләр кубарылган чакта,
Каләм әле кулларымда чакта,
Килгән чакта котылгысыз картлык,
Аралашкан чакта кайгы-шатлык,
Берсен читкә кагып, берсен тыңлап,
Алган чакта күңел бер сулкылдап,
Горурланып тыштан, көнләп эчтән,
Җәлил буйлап, көньяк-көнбатыштан
Төштем җәйге таңда, бу як төсен,
Чаллы кырларының бар яктысын
Җыйган Җәлил, күреп, йөреп чыктым.
Урамына кадәр Тынычлыкның
Төштем таңда, йортлар салып анда
Шул Тынычлык бара заводларга.
Бу шәһәрдә кайда син булма
– Юлыгасың килеп символга.

Җәлил – урам, алдым сюжет итеп,
Урам бетәр, бетмәс сүзем җитеп.
Җәлил – күпер, зәңгәр челтәрле,
Челтәрләрен еллар сүтәрме?
Чоңгылына Кама суыра кебек,
Барам мин дә гүя шунда кереп.
Кама бөек, көчле ихтыяры,
Уйларымның яры – ике яры.
Ике яры – ике кысасы,
Хисләремне шунда кысасы.
Каманы соң буламыни тар дип,
Кама түгел, суыра мине тарих.
Кама яры кебек таш ярлар
Юк сюжетта, сүтеп ташларлар.

Җәлил буйлап көньяк-көнбатыштан –
Әсәремә шул керешкән очтан –
Мин атладым, юк тыныч төш җирдә,
Тыныч түгел бүген мин дә, син дә,
Әллә җомга аңа, әллә шимбә,
Язмышыннан хафаланып Шилнә,
Йөрәгендә кайнап туган хисен,
Бөтен хисен шунда түгәр өчен,
Корыч заводлары арасында
Тарихына таба ашыга ул да.
Җитсә көче тагы өч адымга,
Ташланыр күк Кама кочагына.
Качып-посып кына юлга чыккан,
Алдында тау-киртә, ком-балчыктан,

Тузгып җирдә бөтен ком очканда,
Башын төрткән бетон корпусларга,
Котылырга теләп йөз бәладән,
Озын тимер кебек өзгәләнгән.
Бульдозерлар атлый аның аша,
Бала-чага аста чупылдаша.
Ике туган – ике бәләкәчкә:
Шилнә белән безнең Мәләкәскә,
Кочаклашып юлда, юк, үлмәскә,
Үз уйларым белән мин бәхәстә.

Төштем таңда, уйда алачыклар,
Уйда яшьлек, уйда алан, чыклар,
Тугайларда һаман минем чапкыр,
Ялларына мин тотынып чаптым.
Болын буйлап, Ык тамагы буйлап,
Сызылып аткан Ык таңнары буйлап,
Белми йокы, белми көн-төннәрен,
Кудым монда мин ат көтүләрен.
Бертуктаусыз кудым, мин армадым,
Авылымда туган хыялларның
Ишеттем мин шунда чагымда
Якынайган тавышын Чаллыга.
Тыңлап кырдаҗилнең улауларын,
Тыңлап тавышын арба-олауларның,
Буйларыннан Кама, Иделнең
Елларны мин монда өердем.
Чапкан печән исе, дегет исе,

Искә төште кинәт бөтенесе...
Юллар тыгыз, шундый тыгыз еллар,
Барсы бергә килеп тыгылдылар,
Өерләре белән ат-гасырлар
Агылдылар КамАЗ капкасыннан.
Көтү-көтү атлар «Батыр»ларда,
Батырлар юл яра гасырларга.

Төп төпләгән, чәер кайнаткан,
Ләззәт тапкан ипи-кайрактан.
Үз эшендә тырыш, ат күк күндәм,
Бу тормышны гел зур итеп күргән
Әхмәтҗаннар төште арбалардан,
Күпме еллар килеп, армаганнар.
Кулын куеп ябык яңагына,
Яңа йортка, байның чарлагына
Исе китеп читтән карап торган,

Хыялларга безнең канат куйган,
Караңгыда күзе очкын чәчкән,
Бер әкиятне безгә өч көн рәттән
Сөйли торгач, шунда изрәп киткән.
Ак шәһәрләр безгә ижат иткән
Әхмәтҗаннар эре атлап шуннан –
Агылдылар КамАЗ капкасыннан...

Искә төште бар да, чагыштырам,
Үткәннәрем карый сагыш белән.
Идел. Ачлык... Суда чабаклар...
Чабаклар күк кипкән яңаклар.
Тиф тә ачлык. Арган ил йөзенә –
Моннан торып Арал диңгезенә
Ленин салган аваз бу ярларда –
Кама яры – калын диварларда
Калган яңгырап: Арал, балыкчылар!
Коткарыгыз, сезгә барлык чорлар
Укыр рәхмәт, диңгез илне бага,
Коткарыгыз, сигез миллион бала
Һәлак була... Санаусыз күп эшләр...
Һәлак була сабан сөрер кешеләр,
Белүчеләр серен, җирнең уен,
Җиде миллион алар, җиде миллион...
Идел сезгә игенләтә түләр,
Киләчәктә икеләтә түләр...
Дымы белән диңгез-аралларның,
Ачлык, тифтән исән калганнарның
Балалары, арчып кар базларын,
Сала җирнең бүген КамАЗларын.
Карый алар КамАЗ түбәсеннән,
Шул биеклек хәтта түбән сыман.
Бурычларым түләп мин Аралга,
КамАЗ буйлап атлыйм бүген алга.

Атлыйм алга, читкә чөяр төсле
Мине яшьлек, таза, чибәр, көчле.
Без башкарган эшне башкаруын
Беләм, ләкин бүтән, башка буын.
Минем буын төсе? Төсләр, төсләр...
Днепрогэслар, сугыш һәм Ржевлар...
Тугры булып биргән антларыма,
Җитмеш өчнең февраль-мартларында,
Җыена торгач, бу көн бер җитте дип,
Без сугышкан син шул Ржевмы дип,
Базарда ат күреп гашыйк булган,

Карап төсен, озак басып торган
Сәер кеше сыман, тирән сердә
Утырган тын йортлар тирәсендә
Мин әйләндем, төсләр җиргә сеңә,
Саклый бу җир солдат төймәсен дә.
Яңа буын ләкин ача барды,
Ачкан кебек иске акчаларны.
Ржев. Идел. Карлар ярма-ярма
Бөтен якты Идел ярларында.
Анда тормыш, үткән, бүгенгесе,
Ул кайда юк минем буын төсе,
Җил ашаган, кырыс карашлылар,
Яланнарда калын кар астыннан
Карый һәйкәл, фоторәсемнәрдән,
Кая гына алар чәчелмәгән!
Мин КамАЗда гүя төштем эзләп,
Шул буынның ерак төсен эзләп.

Вагоннарга кердем – рәсемен күрдем,
Давылларга кердем – яшенен күрдем,
Көчле яшен (истә шул чагым)
Чалып узды йөзен Мусаның.
Июнь ае, июнь ахырлары,
Кем дә аны монда чакырмады,
Ул КамАЗда... КамАЗ, син хупларсың,
Мондый чакта нигә ул купмасын!
Зур калалар көтеп яталар дип,
Уйнасыннар кулда балталар дип,
Шул хыялы бәлки КамАЗ булып
Яшәткәндер аны гел яздырып.
Хыял, хыял, нинди ләззәтле син,
Азатлыкны җырла, хезмәтне син.
Йортлар торгыз, ташка ташны сыла,
Әйлән, әверел, КамАЗ ташчысына.
Батырлыкның заман барсын хуплар,
Корчагиннар купты, Матросовлар,
Купты дотлар... Юл-туплары белән,
Фронтлары-Волховлары белән,
Кар-давыллы сугыш чоры белән,
Моабитның кара шомы белән
Купты Җәлил, бергә кушылдылар,
Барсы-барсы менә шушы еллар
Булды миңа кабат кайткан сыман,
Агылдылар КамАЗ капкасыннан.

Масштабы чорның, бөтен эше,

Бөтен рухы чорның, омтылышы
Алар рухы белән кушылганда,
Ашкындырган чакта эшем алга,
Очраштырды заман, Гәрдәле
Тәрәзәдән алып пәрдәне,
Әйләнгәндә үзе фундаментка,
Җыенганда үзе шунда утта
Кайнатырга безнең көн өчен
Иң шәп корыч – КамАЗ корычын,
Таң яктысы уйнап ярларда,
Чагылганда «Пресс-рам»нарда,
Чор яктысын җыйган рамнарга
Сихерләнеп карап барганда,
Очраштырды, бәйрәм бүген минем,
Яшьлеккә кул бирде минем буын.
Без көн саен искә алганнарның
Һәм сугышта исән калганнарның
Балалары, үтәп наказларны,
Сала бүген гигант КамАЗларны.

КамАЗ – җавап. КамАЗ – киң адымнар,
Кайда яшьлек – анда «Гренада»лар,
Кайда яшьлек — анда романтика,
Бу урынны безнең заман тиккә
Сайламаган. Кама – жирәбә,
Биек урын, йөзгә җил бәрә...
Улы-кызы якут, калмык, финнең,
Бу КамАЗда бөтен ягы җирнең
Очраша күк, җиңел атларга.
Татарча сүз катып хантларга,
Төштем бергә, минем алдан барган
Гагаузлар белән молдаваннар
Күптән таныш, артта калды эзләр;
Молдавия, дала, гагаузлар...
Төштем Кама ярларына табан,
Сәлам сиңа, авар, табасаран,
Рәсулларга, Кайсыннарга сәлам,
Гасырларга калсын, әйдә, сәлам!
Төрле телләр – төркемнәргә сәлам,
Яңа буын Теркиннарга сәлам,
Төштем көйләп шулар уртасында
Үз телемдә, телем утта-суда
Чыныккан тел, бай ул, телем – Чулман,
Яши җирдә Чулман аккан чордан!

Йөрдем җәен, январенда йөрдем,

Йөрдем, Кама ярларында йөрдем.
Юк салкын җир Чаллы яланы күк,
Җиле тимер чана табаны күк.
Җиле битне ялап ала төсле,
Кары түгел, ялан ага төсле,
Дала җиле (усал, ачы, кисте)
Кисте битне, «РИЗ» дип, «РИЗ» дип кисте.
«РИЗ» шыксыз дип миңа кем тукыды?
Бар үз күге аның, үз офыгы,
Тышта январь, буран бәрә йөзгә,
Бер офыктан бер офыкка «РИЗ»да
Очты кошлар, рәхәт күңелләргә,
Җылынды күк хәтта тимерләр дә.
Очты кошлар... КамАЗ субайларын
Сукты яшьлек, чорны соң аңладым.
Җылы төшкә кошлар сыенган күк,
Канат җилпеп, сайрап сөенгән күк,
Үскән саен КамАЗ, кеше монда
Ни өчендер ныграк Есенинга
Җаны-тәне белән елышты күк,
Җылысь күп, беләм, җылысы күп.
Кем син, ташчы яки янар күзле
Ак шәһәрләр кызы – маляр кызмы,
Героемы безнең китапларның?
Түбәләрен ябып гигантларның,
Төшеп җиргә, кайнар тимер мичкә
Ике кулың куеп, бирелеп хискә,
Сөйләүчеме безгә зәвыкларын,
Кабызучымы мәктәп, зал утларын?
Элек тып-тып яткан чагын уйлап,
Шул бәрәңге бакчалары буйлап,
Бер почмакка кысып дала аен,
Башлап монда КамАЗ трамваен
Йөртүчеме? Тәмам төзелеп КамАЗ,
Бәхәс, шау-шу бераз тынып калгач,
Чыгып кырга, куеп җилгә яңак,
Онытылган күк Дугадан соң солдат,
Син торырсың басып, уйда еллар,
Кызларың бар инде, улларың бар,
Син торырсың басып, синең сүзләр:
Бу ак шәһәр, парк, сүзләр – «РИЗ»лар.
Йөрдем янып Тольяттилар буйлап...
КамАЗларда таң аттырам уйлап...
Мәктәбендә туктап «Вахитов»ның
Юандым мин. Үттең, вакыт, үттең...
Бу мәктәптә күңел боекмады,

Сагынырмын мин ул минутларны.
Сагынырмын озак, уттайларын –
Киләчәкнең эзләп Тукайларын,
Кердем залга, залда – өметләрем.
Эзләүләрдән тора гел үткәнем,
Зал, трибуна, шигырь, алкышлар,
Тукайлар юк, әлегә – Апушлар...
Шигырь укып мин шул Апушларга,
Йөрдем килеп монда яз, кышларда.
Талантларны мәктәп, вакыт туплар,
Шаулар яшьлек, үсәр Вахитовлар.
Заман кулы баштан сыйпар, назлар,
Тукайны да бирсә бу КамАЗлар...

Йөрдем янып... Алда кызыл ярлар
Зәңгәр дөнья эченә сузылганнар,
Сузылганнар ерак тау-үрләрем,
Тау-үрләрем – минем тамырларым,
Мендем атлап тарих баскычыннан,
КамАЗ баскычыннан, баш очымнан
Тора үтеп җитез керәшәләр,
Кешеләргә шатлык өләшәләр.
Чаллы исеме гүя ярдан чыкты,
Дөньяга ул чыңлап-яңрап чыкты,
Хәтерләтте очкан керәшәне,
Шушы ярда аның киләчәге.
Кызыл ярлар... Калын катлаулары
Әйтерсең лә дәвер капкалары,
Алып бабай куйган күгәннәрен,
Кердем, йөрдем теркәп күргәннәрем.
Урманнары буйлап Илбактының –
Киләчәге буйлап ил бәхетенең
Гизде уем... Карап сокланырга
Мендем таңда Кама сыртларына,
Рәхмәт сезгә, көн дә мине көткән,
Яшәртүче яңа биеклекләр!

Июнь, 1974

**КАМАЗ АЛМАГАЧЛАРЫ**

Сез – безнең узган яшьлеккә
Бу җирдә алмаш бары.
Сездә дәвамы яшьлекнең,
КамАЗ алмагачлары.
Киләсез урамнар буйлап,
Әйтерсең загстан сез,
Язмышның үзе белән дә
Шушында танышкансыз. Сез
аяк баскан җир – КамАЗ.
Тамырлар чыккан шуннан...
Дисәләр:
– Кайдан? Әйтегез:
Дәверләр капкасыннан... Сез –
безнең узган яшьлеккә Бу җирдә
алмаш бары, Якты, хәерле юл сезгә,
КамАЗ алмагачлары.